КАРАР (РЕШЕНИЕ)

"Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

17 ноябрь 2025 ел № 1

“Иҗтимагый хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 20.03.2025 N 33-ФЗ Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы поселогы" муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы, Саба шәһәр җирлеге Советының17.12.2021 елның 39 номерлы "Торак пунктларда гражданнар җыелышын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында" карарына таянып 2025 елның 10 ноябреннән 14 ноябренә кадәр узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән «Сез 2026 нче елда “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы бистәсе” муниципаль берәмлегенә керүче Байлар Сабасы торак пунктында, яшәү урыны буенча “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Җир асты суларының (чишмәләрнең) табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (Байлар Сабасында чишмәләрне төзекләндерү, һәм ремонтлау)
- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияларне төзекләндерү (Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә һәйкәлләрне төзү, ремонтлау)
- Тротуарларны төзү, ремонтлау (Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең тротуарларын, лотокларын ремонтлау һәм төзү)
- Торак пункт территориясен төзекләндерү (Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә паркларны, яр буен, балалар һәм спорт мәйданчыкларын, халык күпләп ял итә торган башка урыннарны тоту, урнаштыру, ремонтлау һәм җиһазлау)
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә юл-урам челтәре кырыйларын ремонтлау) соравын үз эченә алган узган җыеннар нәтиҗәләре нигезендә гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 6 269 катнашучы кертелгән, шуның 3 385 се тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

“ӘЙЕ" позициясе өчен гражданнар җыенында катнашкан 3 298 кеше тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 87 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе» муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы бистәсе торак пунктында халык җыенын үткән дип, аның нәтиҗәләрен чын дип танырга.

2. «Сез 2026 нче елда “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы бистәсе” муниципаль берәмлегенә керүче Байлар Сабасы торак пунктында, яшәү урыны буенча “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

- Җир асты суларының (чишмәләрнең) табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (Байлар Сабасында чишмәләрне төзекләндерү, һәм ремонтлау)
- Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) булмаган һәйкәлләрне төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияларне төзекләндерү (Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә һәйкәлләрне төзү, ремонтлау)
- Тротуарларны төзү, ремонтлау (Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең тротуарларын, лотокларын ремонтлау һәм төзү)
- Торак пункт территориясен төзекләндерү (Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә паркларны, яр буен, балалар һәм спорт мәйданчыкларын, халык күпләп ял итә торган башка урыннарны тоту, урнаштыру, ремонтлау һәм җиһазлау)
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсендә юл-урам челтәре кырыйларын ремонтлау) карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/saba адресы буенча һәм җирлектә урнашкан мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге башлыгына җибәрергә.

Саба шәһәр җирлеге башлыгы Р.М. Хәсәнов